ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЗАКОНЫ**

**“Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2018 елның 20 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 7 (II өлеш); 2005, № 2, № 4 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 11; 2006, № 4, № 7 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш), № 8; 2008, № 1; 2009, № 1, № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2011, № 3, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2013, № 3, № 7, № 12 (I өлеш); 2014, № 5, № 11 (VI өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2016, № 3, № 5, № 6 (I өлеш), № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 55 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) $14^1$ статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

2) 15 статьяда:

а) 1 өлештә:

5 пунктта “җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының сакланышына муниципаль контрольне гамәлгә ашыру,” сүзләреннән соң “юл хәрәкәтен оештыру,” сүзләрен өстәргә;

18 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“18) каты коммуналь калдыкларны туплау (шул исәптән аерым-аерым туплау) һәм ташу эшчәнлеген оештыруда катнашу;”;

19 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“19) җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, аларның үтәлешен тикшереп тору, күрсәтелгән кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру, шулай ук шәһәр урманнарыннан, җирлекнең торак пунктлары чикләрендә урнашкан махсус саклана торган табигать территорияләре урманнарыннан файдалануны, аларны саклауны, яклауны, торгызуны оештыру;”;

б) 3 өлештә:

9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“9) җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, аларның үтәлешен тикшереп тору, күрсәтелгән кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру;”;

14 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“14) каты коммуналь калдыкларны туплау (шул исәптән аерым-аерым туплау) һәм ташу эшчәнлеген оештыруда катнашу;”;

3) 16 статьяда:

а) 1 өлештә:

5 пунктта “муниципаль район чикләрендәге торак пунктлар чикләреннән тыш җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының сакланышына муниципаль контрольне гамәлгә ашыру” сүзләреннән соң “, юл хәрәкәтен оештыру” сүзләрен өстәргә;

14 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“14) тиешле муниципаль районнар территорияләрендә каты коммуналь калдыкларны туплау (шул исәптән аерым-аерым туплау), җыю, ташу, эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, күмү эшчәнлеген оештыруда катнашу;”;

25 пунктка “ихтыяр белдерүгә” сүзләреннән соң “(волонтерлыкка)” сүзен өстәргә;

34 пунктта “, муниципаль районның авылара территориясе чикләрендә планлаштыру структурасы элементларына исемнәр” сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 2 өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

4) 17 статьяның 1 өлешендә:

а) 5 пунктта “шәһәр округы чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының сакланышына муниципаль контрольне гамәлгә ашыру,” сүзләреннән соң “юл хәрәкәтен оештыру,” сүзләрен өстәргә;

б) 24 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“24) каты коммуналь калдыкларны туплау (шул исәптән аерым-аерым туплау), җыю, ташу, эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, күмү эшчәнлеген оештыруда катнашу;”;

в) 25 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“25) шәһәр округы территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, аларның үтәлешен тикшереп тору, күрсәтелгән кагыйдәләр нигезендә шәһәр округы территориясен төзекләндерүне оештыру, шулай ук шәһәр урманнарыннан, шәһәр округы чикләрендә урнашкан махсус саклана торган табигать территорияләре урманнарыннан файдалануны, аларны саклауны, яклауны, торгызуны оештыру;”;

г) 33 пунктта “ихтыяр белдерүгә” сүзләреннән соң “(волонтерлыкка)” сүзен өстәргә;

5) 20 статьяның 1 өлешендәге тугызынчы абзацына “, җәмәгатьчелек фикер алышулары” сүзләрен өстәргә;

6) 21 статьяның 5 өлешендәге беренче абзацында “Торак пунктлар арасындагы территорияләрдә яңа төзелгән муниципаль берәмлек оештырылган очракта яисә” сүзләрен төшереп калдырырга;

7) 22 статьяның 8 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 14 пункт өстәргә:
“14) муниципаль берәмлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау.”;

8) 35 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“35 статья. **Гражданнарның ихтыярый салым акчалары**

1. Гражданнарның ихтыярый салым акчалары дигәндә гражданнарның җирле әһәмияттәге конкрет мәсьәләләрне хәл итү өчен башкарыла торган бер тапкыр түләүләре аңлашыла. Гражданнарның ихтыярый салым тәртибендә түләүләренең күләме муниципаль берәмлектә (җирлек, шәһәр округы составына керүче торак пунктта) барлык яшәүчеләр өчен тигез абсолют күләмдә билгеләнә, моңа муниципаль берәмлектә (җирлек, шәһәр округы составына керүче торак пунктта) яшәүчеләрнең гомуми санының 30 проценттан артмаган һәм түләүләрнең күләме киметелергә мөмкин аерым категориядәге гражданнар керми.

2. Гражданнарның әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән бер мәртәбә башкарыла торган түләүләрен кертү һәм алардан файдалану мәсьәләләре җирле референдумда, ә “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” Федераль законның $25^{1}$ статьясындагы 1 өлешенең 4 һәм $4^{1}$ пунктларында каралган очракларда гражданнар җыенында хәл ителә.”.

**2 статья**

1. Әлеге Закон, бу статьяда үз көченә керүнең башка сроклары билгеләнгән нигезләмәләреннән тыш, рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 3 пунктының “а” пунктчасындагы бишенче абзацы, 4 пунктының “г” пунктчасы 2018 елның 1 маеннан үз көченә керә.

3. Әлеге Законның 1 статьясындагы 2 пунктының “а” пунктчасындагы икенче абзацы, 3 пунктының “а” пунктчасындагы икенче абзацы, 4 пунктының “а” пунктчасы 2018 елның 30 декабреннән үз көченә керә.

4. Әлеге Законның 1 статьясындагы 2 пунктының “а” пунктчасындагы өченче һәм дүртенче абзацлары, “б” пунктчасындагы дүртенче һәм бишенче абзацлары, 3 пунктының “а” пунктчасындагы өченче һәм дүртенче абзацлары, 4 пунктының “б” пунктчасы 2019 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2018 ел, 16 март
№ 10-ТРЗ